ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2025 г. Заинск № 103

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы “Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында” карарына**

«Татарстан Республикасы спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы «Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына (17.12.2018 ел №1864, 22.03.2019 ел №151, 05.11.2019 ел №574, 17.12.2019ел №646, 20.12.2019 ел, №648, 10.06.2020ел № 247, 01.07.2020 ел №298, 14.10.2021 № 617, 12.11.2021ел № 680, 27.01.2022ел № 44, 04.08.2022ел № 389, 25.01.2023ел № 34, 01.09.2023 ел № 693, 10.07.2024 ел № 389, 14.01.2025 ел № 09 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Үз көчен югалткан дип танырга:

а) «Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерләүче муниципаль физкультура спорт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә» (5 нче кушымта);

б) «Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерләүче муниципаль физкультура спорт учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең

һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларына эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә» (6 нчы кушымта).

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Э. Галеев

Юрисконсульт
Тимеркаева И.Г.
(85558) 28044